**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЮТАЗЫ АВЫЛ БАШКАРМА**
**КОМИТЕТЫ**

**423962, Ютазы авылы,**
**Дмитров урамы, 2**
**тел. 4-00-91**
**факс: 8 (85593) 4-00-93**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЮТАЗИНСКИЙ СЕЛЬСКИЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ЮТАЗИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**423962, с. Ютаза,**
**ул. Дмитрова, д.2**
**тел. 4-00-91**
**факс: 8 (85593) 4-00-93**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**30 ноябрь 2021г.** **№32**

2022 елда Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегендәге Ык торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы карарының 25.1, 56 санлы маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 июлендәге 8 санлы карары белән кабул ителгән Уставының 14 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Ютазы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2021 елның “14” декабрь 09.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Ык авылы, Яшел урам, 4 йорт адресы янындагы торак йорт янында 2022 елда Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Ык торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«2022 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге, Ык торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булмаган һәр кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 һәм 2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган тормыш иптәшләре, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Ык торак пунктының Яшел урамында юл-урам челтәре торышын норматив хәлгә китерү (смета нигезендә юл салу: вак ком-таш катнашмасы сатып алу, нигез әзерләү, алып кайту, салу, проект-смета документларын әзерләү, килешү нигезендә эшләр өчен түләү);

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Ютазы авыл җирлеге Башкарма комитетына халык җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

4. Әлеге карарны Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru, һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru.

5. Әлеге карар басылып чыккан көннән (халыкка җиткерелгән көннән) үз көченә керә.

Ютазы муниципаль районы
Ютазы авыл җирлеге башлыгы Р.М.Галимов